# КАРАР

## Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Югары Налим авыл җирлеге составына керүче Югары Налим торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**21.12.2021** **№ 2**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2021 елның 21 нче декабрендә булып узган гражданнар җыены нәтиҗәләре нигезендә сорау буенча бе ркетмә төзелде: "Сез 2022 елда Югары Налим авыл җирлегенең Югары Налим торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым акчаларын кертүгә, көндезге формада белем алучы студентлардан, I төркем инвалидларыннан, ялгыз өлкәннәрдән тыш, һәм алдагы эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрүгә килешәсезме:

- мәгълүмат тактасы сатып алу һәм урнаштыру;
- балалар мәйданчыгын төзекләндерү (балалар мәйданчыгы өчен спорт-уен элементларын сатып алу һәм урнаштыру);
- зиратны төзекләндерү (агач кисү);
- Елга аръягы урамындагы юлга яңа материал өстәп вак таш түшәмәсенең профилен төзәтү.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:
сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 228 кеше, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 141 кеше кертелгән.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен 141 җыенда катнашучы тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен 0 җыенда катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Югары Налим авыл җирлегенең Югары Налим торак пунктында гражданнар җыенын узган дип танырга, халык җыены нәтиҗәләре-дөрес.

2. Түбәндәге сорау буенча карар кабул итәргә: «Сез 2022 елда Югары Налим авыл җирлегенең Югары Налим торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым акчаларын кертүгә, көндезге формада белем алучы студентлардан, I төркем инвалидларыннан, ялгыз өлкәннәрдән тыш, һәм алдагы эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрүгә килешәсезме:

- мәгълүмат тактасы сатып алу һәм урнаштыру;

- балалар мәйданчыгын төзекләндерү (балалар мәйданчыгы өчен спорт-уен элементларын сатып алу һәм урнаштыру);

- зиратны төзекләндерү (агач кисү);

- Елга аръягы урамындагы юлга яңа материал өстәп вак таш түшәмәсенең профилен төзәтү. – соравы буенча карарны кабул ителгән дип танырга.

3. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында бастырып чыгарырга, «Татарстан Республикасы Хокукый мәгълүматның рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Югары Налим авыл җирлеге башлыгы Л.И. Сибгатуллин